СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД ИННОПОЛИС»
ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район, Республика
Татарстан, 420500

МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ
«ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ»
СОВЕТЫ
Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

РЕШЕНИЕ — КАРАР

13.06.2024 — № 32-178

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрьдәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлеше, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Югары Ослан районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Иннополис шәһәре Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Иннополис шәһәре Башкарма комитетына:

- Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

- Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетын кабул итү турында» «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 15 декабрендәге 26-148 номерлы

карарына үзгәрешләр кертү хакында» муниципаль берәмлек Советы карары проектын бюджет законнары нигезендә эшләргә һәм карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат: https://pravo.tatarstan.ru/, рәсми порталында рәсми рәвештә бастырылган көннән үз көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән https://verhniy-uslon.tatarstan.ru/, һәм Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан ителергә тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Иннополис шәһәре Мэры Р.Р. Шагалеев